| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июня 2016 г. № 3276

Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешнең 2 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015-2020 елларга «Торак «федераль максатчан программасы турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары,Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә»;

2) административ регламентның 1.4 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015-2020 елларга «Торак «федераль максатчан программасы турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары;»

3) административ регламентның 1.4 пунктының бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4) административ регламентның 1.4 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары»;

5) административ регламентның 1.4 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның «2016-2020 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 1078 номерлы карары»;

6) административ регламентның 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов